СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

21.08.2023 с. Верхний Услон № 36-491

Югары Ослан муниципаль районының 2023 елның 1 яртыеллыгы өчен бюджеты үтәлеше турында

Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы рәисе Колесова Е.Е. Югары Ослан муниципаль районының 2023 елның 1 яртыеллыгы бюджеты үтәлеше турында мәгълүматларын тыңлап фикер алышканнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы бюджетының 2023 елның 1 яртыеллыгында үтәлүе турындагы мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).

2. Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетларына Финанс-бюджет палатасы, Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә тәкъдим итәргә:

- бюджетның барлык дәрәҗәләренә керемнәрне мобилизацияләү буенча чаралар күрергә һәм эшне көчәйтергә, салым һәм салым булмаган керемнәр буенча план билгеләнешләренең максималь үтәлешен тәэмин итәргә;

- салым бурычларын һәм салым булмаган керемнәр буенча бурычларны каплау эшен дәвам итәргә;

- салым һәм салым булмаган керемнәр керүнең артта калган шартларында бюджетларның беренче чираттагы һәм социаль әһәмияткә ия чыгымнары буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- бюджет акчаларын сакчыл, экономияле тоту өчен чаралар күрергә;

- бюджет акчаларының калган өлешләре юнәлешен җитди контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

- яңа чыгым йөкләмәләрен финанслауның чыганаклары булмаган килеш кабул итүгә юл куймаска.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М. Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы
Советының
2023 елның 21 августындагы 36-491
номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районының 2023 елның беренче яртыеллыгында берләштерелгән бюджетын үтәү, мең сум.

| Күрсәткеч атамасы | 2023нче елга план | 2023 елның 1 яртыеллыгы факты | үтәлеш % |
|---|---|---|---|
| Җирле бюджет керемнәре | 885241,3 | 421983,4 | 47,7 |
| 1. Салым керемнәре | 516703,7 | 204716,5 | 39,6 |
| 1.1 физик затлар керемено салым | 326329,1 | 134540,1 | 41,2 |
| 1.2 акцизлар түләүдән кергән керемнәр | 38900,0 | 21724,0 | 55,9 |
| 1.3 салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 46303,8 | 24187,9 | 52,2 |
| 1.4 эшчәнлекнең аерым төрләре өчен кертелгән керемгә бердәм салым | 0,0 | -108,1 | - |
| 1.5 бердәм авыл хуҗалыгы салымы | 638,0 | 323,9 | 50,8 |
| 1.6 салым салуның патент системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 5043,0 | 1835,7 | 36,4 |
| 1.7 физик затлар милкенә салым | 6971,8 | -135,2 | -1,9 |
| 1.8 җир салымы | 86812,0 | 19905,1 | 22,9 |
| 1.9 файдалы казылмалар чыгаруга салым | 3339,0 | 811,3 | 24,3 |
| 1.10 дәүләт пошлинасы | 2367,0 | 1631,6 | 68,9 |
| 1.11 башка керемнәр | 0,0 | 0,4 | - |
| 2. Салым булмаган керемнәр | 47070,3 | 20421,6 | 43,4 |
| 2.1 дәүләт һәм муниципаль милектә булган мөлкәтне кулланудан кергән керемнәр | 20768,0 | 7802,2 | 37,6 |
| 2.2 әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 221,0 | 1077,5 | 487,6 |
| 2.3 башка керемнәр | 26081,3 | 11541,9 | 44,3 |
| 3.Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 321467,3 | 196845,3 | 61,2 |
| 3.1 Башка дәрәҗәдәге бюджетлардан кире кайтарылмый торган керемнәр | 304921,1 | 181593,4 | 59,6 |
| 3.1.1 дотацияләр | 14987,7 | 7494,0 | 50,0 |
| 3.1.2 субсидияләр | 84730,2 | 52505,7 | 62,0 |
| 3.1.3 субвенцияләр | 171096,4 | 106920,3 | 62,5 |
| 3.1.4 башка бюджетара трансфертлар | 34106,7 | 14673,5 | 43,0 |
| 3.2 Дәүләт (муниципаль) оешмаларыннан кире кайтарылмый | 4137,3 | 4241,8 | 102,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| торган кертемнәр | | | |
| 3.3 Дәүләтнеке булмаган оешмалардан кире кайтарылмый торган кертемнәр | 145,0 | 145,0 | 100,0 |
| 3.4 Субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның калдыкларын кире кайтарудан керем | 12264,0 | 12268,2 | 100,0 |
| 3.5 Узган елларның максатчан билгеләнеше булган субсидияләр, субвенцияләр һәм бюджетара трансфертларның калдыкларын кире кайтару | 0,0 | -1413,1 | - |
| Җирле бюджет чыгымнары | 963519,3 | 463441,7 | 48,1 |
| 1. гомумдәүләт мәсьәләләре | 140637,7 | 64829,3 | 46,1 |
| 2. милли оборона | 2402,0 | 1201,0 | 50,0 |
| 3. милли иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге | 7355,0 | 2310,6 | 31,4 |
| 4. милли икътисад | 104620,0 | 27643,8 | 26,4 |
| 5. торак коммуналь хуҗалык | 48044,8 | 12261,2 | 25,5 |
| 6. әйләнә-тирә мохитне саклау | 3560,0 | 0,0 | - |
| 7. мәгариф | 499691,2 | 271971,5 | 54,4 |
| 8. мәдәният, кинематография һәм массакүләм мәгълүмат чаралары | 99264,3 | 54565,2 | 55,0 |
| 9. Сәламәтлек саклау | 292,5 | 104,0 | 35,6 |
| 10. социаль сәясәт | 18648,1 | 7477,7 | 40,1 |
| 11. Физик культура һәм спорт | 32219,2 | 17636,8 | 54,7 |
| 12. бюджетара трансфертлар | 6784,5 | 3440,6 | 50,7 |
| Профицит (+), дефицит (-) | -78278,0 | -41458,2 | 53,0 |

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г. Зиатдинов